ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.09.2024 Казан ш. № 79-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 2023 елның 13 ноябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 13 ноябрендәге 134-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлары өлешендә;»;

3 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

5 һәм 6 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә;

6) «Үтәтү эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын түләтүчегә кире кайтарганда суд приставы-башкаручысы тарафыннан үтәтү эшен тәмамлау турында карар чыгару, әгәр күләме банкротлык турында эш буенча производство ачу өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән башлап биш елдан артык вакыт узган булса;

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пунктча өстәргә:

«$6^1$) Бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү;»;

3 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслый торган әлеге Тәртипнең 2, 2.1 пунктларында күрсәтелгән документларны.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда:

физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүченең вафат булуын таныклый торган яисә аның вафат дип игълан ителүе турында дәлилләүче документ.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлгөн (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ;

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшчәнлек туктатылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктының 5 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда:

штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча производство эшчәнлегенең тәмамлануы һәм производство документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе сәбәпле суд приставы-башкаручысы карары.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктының $6^1$ пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты;

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча производство эшчәнлегенең тәмамлануы һәм производство документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе сәбәпле суд приставы-башкаручысы карары.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 7 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар булган документ;

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча производство эшчәнлегенең тәмамлануы һәм производство документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе сәбәпле суд приставы-башкаручысы карары.

Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган нигезләр булганда:

административ җәза билгеләү турында карар үтәлешен туктату турында карар.»;

5 пунктта «3 пункты» сүзләрен «3 пунктының 3 пунктчасы» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия утырышы йомгаклары буенча, әлеге Тәртипнең 9 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы уздырылган көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.»;

13 пунктта «имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Әлеге Тәртипнең 9 пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмавы турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм белешмә өчен Ветеринария идарәсе башлыгына җибәрелә.».

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы А. Г. Хисаметдинов